2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

**ХӘБӘР**

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү комиссиясе, шәһәр халкына һәм шәһәр территориясендә урнашкан оешмаларга, Шәһәр Советы инициативасы буенча 2020 елның 9 ноябрендә $14^{00}$ сәгатьтә Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча Башкарма комитет бинасының 400 залында 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары (дәвамлылыгы якынча бер сәгать) үткәрелү турында хәбәр итә.

Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 номерлы карары белән билгеләнгән.

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча тәкъдимнәр әлеге хәбәрнең аерылгысыз өлешен тәшкил итүче форма буенча 2020 елның 6 ноябренә кадәр срокта тапшырылырга мөмкин.

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча тәкъдимнәр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шәһәр Уставына, башка муниципаль хокукый актларга туры килергә тиеш.

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423805, Яр Чаллы шәһәре, Х. Туфан проспекты, 23 йорт, 372 кабинет. Элемтә өчен телефоннар: 30-56-79, 30-58-31, эл. почта адресы: nche.fbp@tatar.ru.

Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карар проекты «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталары санында бастырыла һәм «Интернет» челтәрендә www.nabchelny.ru адресы буенча урнаштырыла.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү түбәндәгеләр нигезендә 2020 елның 9 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта башлана:

- шәхесне таныклаучы документ мәгълүматлары – физик затлар өчен;
- юридик затларны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык мәгълүматлары, юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ мәгълүматлары; юридик зат вәкиленең шәхесен таныклаучы документ мәгълүматлары – юридик зат вәкилләре өчен.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары,
финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюкова

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү турындагы хәбәргә кушымта

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проектына тәкъдимнәр тапшыру формасы

| Гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме | 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проектында каралган хокук нормасы | Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карар проектына тәкъдим ителә торган үзгәрешләр | Тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне исәпкә алып, Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карар проектында күздә тотылган хокук нормасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |